# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Чит ил инвесторы катнашындагы хупланган инвестиция проектының статусы турында**

Әлеге Закон "Чит ил инвестицияләре турында" Татарстан Республикасы Законы нигезендә чит ил инвесторы катнашындагы хупланган инвестиция проекты статусы бирүнең хокукый, икътисадый шартларын һәм тәртибен билгели.

Закон Татарстан Республикасы икътисадының өстенлекле юнәлешләрен үстерү буенча актив инвестиция эшчәнлегенә ярдәм итүче шартлар тудыруга юнәлдерелә.

**1 статья. Хупланган инвестиция проектының статусы**

**Инвестиция проекты** - оештыру - хокукый һәм икътисадый гамәлләрне, аларның нәтиҗәлелегенең техник нигезләнешен үз эченә алган, Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты раслаган үрнәк ысулият нигезендә әзерләнгән документлар җыелмасы ул.

**Хупланган инвестиция проекты** - махсус ташламалы статуска ия проект, ул Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты карары тарафыннан бирелә.

**2 статья. Инвестиция проектларын классификацияләү**

Инвестиция проектлары түбәндәге категорияләргә классификацияләнә:

"К" категориясе (эре (крупные) инвестиция проектлары) - аларны гамәлгә ашыру республиканың куллану базарына, халыкның эш белән тәэмин ителешенә һәм Татарстан Республикасының рес-

публика бюджетына мәгълүм дәрәҗәдә нәтиҗәле йогынты ясауны тәэмин итүче проектлар, бу проектлар буенча капитал салулар 10 миллион АКШ долларыннан артып китә, шул ук вакытта гомуми суммада чит ил инвесторының өлеше үз һәм (яисә) заем акчаларының кимендә 45 процентын тәшкил итүе шарт;

"С" категориясе (уртача (средние) инвестиция проектлары) - республика әһәмиятенә ия проектлар, бу проектлар буенча капитал салулар суммасы 2 миллионнан алып 10 миллион АКШ долларына кадәр тәшкил итә, шул ук вакытта чит ил инвесторының өлеше үз һәм (яисә) заем акчаларының кимендә 35 процентын тәшкил итүе шарт;

"М" категориясе (кече (малые) инвестиция проектлары) - төбәк һәм муниципаль мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерелгән проектлар, бу проектлар буенча капитал салулар суммасы 0,1 миллионнан алып 2 миллион АКШ долларына кадәр тәшкил итә, шул ук вакытта чит ил инвесторы өлеше үз һәм (яисә) заем акчаларының кимендә 30 процентын тәшкил итүе шарт.

**3 статья. Инвестиция проектларын хуплау процедурасы**

Хупланган инвестиция проекты статусын алу өчен Татарстан Республикасының Тышкы икътисадый бәйләнешләр министрлыгына гариза кертергә кирәк.

Гаризаның катгый төп өлешен Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты раслаган рәвештәге бизнес-план тәшкил итәргә тиеш.

Татарстан Республикасының Тәэелмәле инвестиция сәясәте буенча ведомствоара комиссия инвестиция проектларына дәүләт экспертизасы үткәрә. "С" һәм "М" категорияле проектлар буенча - тәкъдимнәрне алган көннән бер ай эчендә, ә "К" категорияле проектлар буенча өч ай эчендә үткәрелә.

Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты дәүләт экспертизасы үткәрелгәннән соң 10 көн эчендә карар кабул итә. Инвестиция проектлары кире кагылган дәгъвачыларга бер атна эчендә бу хакта язмача хәбәр ителә.

**4 статья. Инвестиция проектларын сайлап алу тәртибе**

Тәэелмәле инвестиция сәясәте буенча ведомствоара комиссия проектларны әлеге Законның 2 статьясында каралган классификация нигеэендә конкурс буенча сайлап ала. Конкурслар уздыруның шартлары һәм тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан раслана.

**5 статья. Бирелүче ташламаларның төрләре**

Чит ил инвестицияләрен өлешкә кертеп тәэелгән яисә тулысынча чит ил инвесторларына караган хокукый эатларга, гамәлдәге эаконнарда билгеләнгән ташламалардан тыш, Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты карары буенча бер елдан алып биш елга кадәр вакытка, киләчәктә бер елдан алып биш елга кадәр чорга озайтылып, хупланган инвестиция проектын сату өлешендә 50% күләмендә түбәндәге ташламалар бирелә:

продукцияне (хеэмәт күрсәтүләрне) сатудан килгән табышның инвестиция проектларын гамәлгә кертүдән алынучы яисә бу проектларны гамәлгә кертү өчен бирелүче, Татарстан Республикасының республика бюджетына кертелүче керемнәре өлешенә салым түләүдән азат итү;

сатылучы товарлардан (эшләрдән, хеэмәт күрсәтүләрдән) өстәлгән бәяләрнең инвестиция проектларын гамәлгә кертүдән алынган яисә бу проектларны гамәлгә кертү өчен бирелгән, Татарстан Республикасының республика бюджетына кертелүче өлешенә салым түләүдән азат итү;

казылмалар чыгаручы тармакларда акцизлар түләүдән азат итү;

хупланган инвестиция проекты буенча файдаланылучы җайланмага тизләтелгән амортизация нормалары билгеләү.

Хупланган инвестиция проекты буенча ташламалар бирү тәртибе һәм вакытлары, аларның максатчыл кулланылышы Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан раслана.

Хакимиятнең җирле органнары тарафыннан җирле салымнарны түләү буенча ташламалар бирелергә мөмкин, Татарстан Республикасы Хөкүмәте тарафыннан тәэелгән контрактларда катгый рәвештә ташламалар бирү каралган очраклар моңа керми.

**6 статья. Хупланган инвестиция проекты статусын туктату**

Хупланган инвестиция проекты статусы түбәндәгеләргә нигезләнеп туктатыла:

а) хупланган инвестиция проекты статусының Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты карары тарафыннан билгеләнгән гамәли вакыты узгач;

б) бирелгән ташламаларны максатчыл файдаланмаганда;

в) хупланган инвестиция проекты шартларын бозганда.

Хупланган инвестиция проекты статусының гамәлдә булуы Татарстан Республикасының Төзелмәле инвестиция сәясәте буенча ведомствоара комиссиясе бәяләмәсе нигезендә туктатыла һәм бу хакта Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты карар кабул итә.

Хупланган инвестиция проекты статусының гамәлдә булуын 6 статьяның беренче өлешендәге "б", "в" пунктларында каралган нигезләрдә туктату турында карар кабул ителгән очракта, әлеге Законда билгеләнгән ташламаларны алучы хокукый зат үзенә бирелгән ташламаларны тулысынча тиешле бюджетка кертергә тиеш.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Шәймиев

Казан шәһәре,
1996 елның 6 марты
N466